ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРО-МАВРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ МАВРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д. 2а, с. Старое Маврино,
Заинский район, 423537

Үзәк урамы, 2а йорт, Иске Маврин
авылы, Зәй районы, 423537

Телефон, факс 62-0-01. Электронный адрес: Smavr.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**04.08.2023** **№ 16**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 13 маендагы 10 номерлы «Документларның һәм алардан алынган өзекләрнең, васыятьнамәләрнең һәм ышаныч кәгазьләренең күчермәләренең тугрылыгын раслау, җир участогына белешмәләр, йорт хуҗалыкларына белешмәләр, гаилә составы турында белешмәләр, яшәү урыныннан белешмәләр һәм хуҗалык китабыннан өзекләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Документларның һәм алардан алынган өзекләрнең, васыятьнамәләрнең һәм ышаныч кәгазьләренең күчермәләренең тугрылыгын раслау, җир участогына белешмәләр, йорт хуҗалыкларына белешмәләр, гаилә составы турында белешмәләр, яшәү урыныннан белешмәләр һәм хуҗалык китабыннан өзекләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 13 маендагы 10 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Р.Г. Нургалеев**